ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.12. 2019 ел № 21

Хөкем ителгәннәргә җәза үтәү өчен мәҗбүри
эшләр һәм объектлар төрләрен билгеләү

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 16.11.2012 ел, ПР-43-6 номерлы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының карарын үтәү йөзеннән (Россия Федерациясе административ хокук бозулар кодексына 2012 елның 8 июнендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә), мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатларында), административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә һәм законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендәге мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Фома авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Мәҗбүри яисә төзәтү эшләре рәвешендә хөкем ителгәннәр җәзасын үтәү өчен түбәндәгечә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре төрләрен билгеләргә:
- Төзекләндерү: территорияне чистарту, яшелләндерү, җир эшләре, юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.
- Территорияләрне санитар чистарту.
- Йөкне төяү-бушату эшләре.
- Җинаять башкарма инспекциясе белән килештереп башлангыч һәм һөнәри әзерлек таләп итмәгән хезмәт эшчәнлегенең башка һәркем файдалана алырлык төрләре,.
2. «Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү өчен объект итеп Фома авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

3. «Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзәтү эшләре рәвешендәге җәза үтәтү объекты итеп Фома авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.
4. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы буенча Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять-башкарма инспекциясе белән берлектә, төзәтү яисә мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән һәм Фома авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд карарларын үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.

5. «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта һәм мәгълүмати стендларда карар урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Абдрахманов Р.Х.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 21 номерлы карарына

Килештерү кәгазе

«2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм 2020 елга төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында»

(документның исеме һәм атамасы)

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Абдрахманов Р.Х.

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы буенча
Россия ҖҮФХИ ФКУнең
Нурлат муниципальара филиалы начальнигы
эчке хезмәт майоры Р.Ф. Хәмидуллин